КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге составына керүче Керәнне торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

23.08.2022 ел

№ 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары , 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 28 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып 2022 елның 23 августында узган гражданнар җыенында «2023 нче елда Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Керәнне торак пунктында балигъ булган, Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге составына керүче Керәнне торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1200,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

1) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Керәнне торак пунктында, Залесная урамында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (грунт эшләү, комлы нигез салу, вак таштан нигез салу, юл читләрен урнаштыру, сугткәргеч торбалар урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 75 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 39 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 39 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге составына керүче Керәнне торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

2.«2023нче елда Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Керәнне торак пунктында Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге составына керүче Керәнне торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1200,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә" һәм алынган акчаларны

җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме? - дигә
сорау буенча:

1) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Керәнне тора
пунктында, Залесная урамында җирле әһәмияттәге автомобиль юллары
ремонтлау (грунт эшләү, комлы нигез салу, вак таштан нигез салу, юл
читләрен урнаштыру, суүткәргеч торбалар урнаштыру, килешү буенча
эшләр өчен түләү) карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренда Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/michan адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Мичән авыл
җирлеге башлыгы А.Ә.Гәрәев